**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ ҖӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# РЕШЕНИЕ
# КАРАР

**«02» июль 2025 ел** **№ 195**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Җәке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” № 131 – ФЗ, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Җәке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә , Зеленодольск муниципаль районының Олы Җәке авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Җәке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшырырга.:

- җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын паспортлаштыру.

2. Олы Җәке авыл җирлеге башкарма комитетына җирлекнең әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Яшел Үзән муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Олы Яке авылы, Мәктәп урамы, 1 (Советның административ бинасы), Олы Яке авылы, Мәктәп урамы, 1а (Олы авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

Олы Жэке авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе: Ф.А.Фәйзуллина